МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.12.2023 Казан ш. № 21-95-413

“Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтеп булмый дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын кабул итү тәртибен раслау хакында” 01.11.2019 ел, № 21-95-261 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтеп булмый дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к  б и р ә м:

Внести в “Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтеп булмый дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын кабул итү тәртибен раслау хакында” 01.11.2019 ел, № 21-95-261 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтеп булмый дип тану турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын кабул итү тәртибенә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 14.05.2020 ел, № 21-95-85 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның «в»  пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) хосусый эшмәкәр булып торучы гражданинның – Бюджетка түләүләр түләүченең мөлкәтен сатуны тәгалләү яки конкурс производствосын тәгалләү

турында суд актының, шулай ук физик затның – хосусый эшмәкәр сыйфатында эшчәнлеге буенча Бюджетка түләүләр түләүченең түли алмаганлыгын (банкротлыкка чыгуын) тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә, аның Бюджетка түләүләрне туктатуы турында Хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматлардан торган документны.";

5[1] пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) гражданинның – Бюджетка түләүләр түләүченең мөлкәтен сатуны төгәлләү яки конкурс производствосын төгәлләү турында суд актының.»;

6 пунктның «в» пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктның «в» пунктчасында "актлар күчермәләренең" дигән сүзләрне "актның" дигән сүзгә, "суд карарлары күчермәләре" дигән сүзләрне " суд акты" дигән сүзләргә алыштырырга;

8 пунктта:

«в» пунктчасында "кире кайтарганда" дигән сүзләрне "кире кайтаругак бәйле рәвештә" дигән сүзләргә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлектәге «г» пунктчасын өстәргә:

«г) банкротлык турында эштә кулланыла торган процедуралар үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек дәрәҗәдә средстволарга ия булмау сәбәпле, банкротлык турында эш буенча производствоны туктату яки бурычлының түли алмаячагын (банкротлыкка чыгуын) тану турында гаризаны кире кайтару хакында суд акты.»;

8[1] пунктның «в» пунктчасында "юридик затның" дигән сүзләрдән соң "-Бюджетка түләүләр түләүченең" дигән сүзләрне өстәргә;

9 пунктның «в» пунктчасында "күчермәләр", "судьяның, органның, вазыйфаи затның" дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Бу Тәртипнең 4-9 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтеп булмый дип тануның нигезләрен раслаучы документлар пакеты, Бюджет керемнәре администраторына бу Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында күздә тотылган очракның пәйда булуы турында мәгълүмат алынганнан соң, Бюджет керемнәре администраторының структур подразделениеләре әзерләгән мәгълүматлар буенча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты керемнәр бүлеге тарафыннан булдырыла. Документлар активларның кереме һәм чыгымы буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясенә (алга таба – Комиссия) аларның Бюджет керемнәре администраторына алынуыннан соң утыз календарь көне эчендә карап тикшерүгә җибәрелә.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтеп булмый дип тану эшен оештыру максатыннан чыгып, Бюджет керемнәре администраторы боерыгы нигезендә Комиссия булдырыла, аның составына Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары һәм Комиссия әгъзалары керә. Комиссия 8 кешедән тора. Комиссиянең персональ составы Бюджет керемнәре администраторының боерыгы нигезендә раслана.»;

13 пунктны түбәндәгередакциядә бәян итәргә:

«13. Комиссия рәисе:

Комиссия эшенә җитәкчелек итә;

Комиссия утырышларын үткәрә;

Комиссия әгъзалары арасыннан секретаря Комиссия секретарен билгели.

Рәс булмаганда, аның бурычларын Комиссия рәисе урынбасары үти.

Комиссия секретаре:

Комиссиянең делопроизводство алып баруын оештыра;

Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүматлар белән тәэмин итә;

Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча Комиссия эшенә бәйле башка функцияләрне үти.»;

16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтеп булмый дип тану турында мәсьәләне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, керемнәр бүлегеннән документлар алынганнан соң җиде календарь көненнән дә соңга калмыйча, Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) бу Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында һәм (яки) бу Тәртипнең 4-9 пунктларында күрсәтелгән документларда нигезләр булганда – Бюджет керемнәре администраторының бюджет учетыннан гамәлдән чыгарылырга тиешле һәм Бюджетка түләтеп булмаган түләүләр буенча бурычны тану;

б) бу Тәртипнең 2 һәм 3 пунктларында һәм (яки) бу Тәртипнең 4-9 пунктларында күрсәтелгән документларда нигезләр булмаганда – Бюджетка түләтеп булмаган түләүләр буенча бурычны танымау турында. Әлеге карар әлеге бурычны Бюджетка түләтеп булмауны таны турында мәсьәләне кабат карап тикшерүгә комачауламый.»;

17 пунктта "Комиссия рәисе" дигән сүзләрне "утырышта рәислек итүче" дигән сүзләргә алыштырырга;

18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Бу тәртипнең 16 пунктындагы "а" пунктчасында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы йомгаклары буенча, Комиссия утырышы үткәрелгәннән соң ун эш көне эчендә, Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтеп булмавын тану турында карар проекты әзерләнелә.

Комиссия утырышы уздырылганнан соң унбиш эш көне эчендә бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтеп булмый дип тану турында комиссия карары бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтеп булмый дип тану турында түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт (алга таба - Акт) белән рәсмиләштерелә:

а) оешманың тулы исеме, (физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме) (соңгысы булганда);

б) салым түләүченең идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры, оешманың-салым түләүчене исәпкә кую сәбәпләре коды (физик затның-салым түләүченең идентификация номеры (булган очракта);

в) бурыч барлыкка килгән түләү турында мәгълүмат;

г) бюджетка түләүләр буенча бурычны исәпкә алуга нигез булган Россия Федерациясе бюджетлары керемнәренең классификациясе коды, аның атамасы;

д) Бюджетка түләүләр буенча бурыч суммасы;

е) Бюджетка тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

ж) Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтеп булмый дип тану турында карар кабул итү көне.

Акт ике нөсхәдә төзелеп, утырышта рәислек итүче һәм утырышта катнашкан Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

Бу Тәртипнең 16 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтеп булмый дип тану өчен нигезләрнең булмавы хакында мәгълүмат чагылдырыла.”;

19 пунктта “көннәр” дигән сүздән соң “аны имзалаган көннән” дигән сүзләр өстәргә;

20 пунктта “Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык Департаменты” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

Бу Тәртипкә № 2 кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

Министр Р.Р. Гайзатуллин